**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы рус теле комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы рус теле комиссиясе турында» 2022 елның 20 маендагы ПУ-355 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 14 мартындагы 152 номерлы һәм 2023 елның 28 ноябрендәге 814 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы рус теле комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Г.Ф. Вәлиеваны, Т.С. Куракинаны, Л.Н. Рыбаковаңы, К.Г. Яковлевны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Вәлиуллин Ренат Нәкыйф улын – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы рәисе урынбасары – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы Советы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатын (килешү буенча);

Зарипов Айрат Ринат улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисен (килешү буенча);

Исламова Елена Анатольевнаны – «Бәхетле язмышлар» хәйрия фонды директорын (килешү буенча);

в) Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Л.Е. Бушканецның – «Татарстан Республикасы Милли музее» дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе филиалы – Л.Н. Толстой музее мөдире, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты Лев Толстой исемендәге рус филологиясе һәм мәдәнияте югары мәктәбенең рус әдәбияты һәм аны укыту методикасы кафедрасы профессоры, Россия фәннәр академиясе Дөнья мәдәнияте тарихы советының Чехов комиссиясе әгъзасы (килешү буенча)»;

В.В. Шаталовның – «Татарстан Республикасының «Мәдәниятләр һәм багланышлар үзәге» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе, Татарстан Республикасында «Тотал ь диктант» рус теле буенча халыкара мәгърифәти акциясе координатордашы (килешү буенча)»;

г) Комиссия әгъзасы С.А. Мостафинаның фамилиясен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Галиева-Мостафина».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 13 гыйнвар
№ 2